РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» июля 2026 ел г. Альметьевск №1252

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы территориясенең муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурста катнашуга гаризалар критерийларын бәяләү өчен даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын төзү һәм алып бару тәртибен, муниципаль маршрутларны билгеләү, үзгәртү һәм бетерү, шкалалар тәртибен раслау турында» 2016 елның 24 мартындагы 466 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы территориясенең муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурста катнашуга гаризалар критерийларын бәяләү өчен даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын төзү һәм алып бару тәртибен, муниципаль маршрутларны билгеләү, үзгәртү һәм бетерү, шкалалар тәртибен раслау турында» 2016 елның 24 мартындагы 466 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 3 сентябрендәге 1310 номерлы, 2021 елның 22 ноябрендәге 1675 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

2 бүлекнең 2.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Муниципаль маршрутлар реестры таблица рәвешендә рәсмиләштерелә (тәртипкә кушымта) һәм түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала:

1) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутының теркәү номеры;

2) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутының тәртип номеры;

3) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты исеме даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча башлангыч тукталыш пункты һәм соңгы тукталыш пункты исемнәре рәвешендә;

4) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча аралык тукталыш пунктлары исемнәре;

5) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча тукталыш пунктлары арасында транспорт чаралары хәрәкәте күздә тотыла торган урамнар, автомобиль юллары исемнәре;

6) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутының озынлыгы;

7) пассажирларны утырту һәм төшереп калдыру тәртибе;

8) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу төре (җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу яисә җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу);

9) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларының төрләре, класслары, экологик характеристикалары;

10) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдаланырга рөхсәт ителә торган һәр класстагы транспорт чараларының максималь саны;

11) расписание (Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2024 елның 18 апрелендәге 135 номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча);

12) пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның сыйфатына йогынты ясый торган транспорт чаралары характеристикалары һәм һәр класстагы транспорт чараларының шундый характеристикалы өлеше тиешле класстагы транспорт чараларының максималь саныннан процентларда (әгәр әлеге белешмәләр даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутын билгеләү яисә үзгәртү турындагы карар, контракт яисә ачык конкурста катнашучының ачык конкурста катнашуга заявкасы белән каралган булса, аңа даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы бирелгән җайга салынмый торган тарифларга);

13) транспорт чараларын эксплуатацияләүнең максималь срогы (әгәр әлеге белешмәләр контрактта яисә җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы бирелгән ачык конкурста катнашучы тарафыннан бирелгән ачык конкурста катнашуга гаризада каралган булса);

14) юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар тарафыннан даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра башлау датасы;

15) исеме, булу урыны (юридик зат өчен), юридик зат төзү турындагы язманың Дәүләт теркәү номеры, фамилиясе, исеме һәм, әгәр булса, атасының исеме, яшәү урыны (индивидуаль эшкуар өчен), индивидуаль эшкуарны дәүләт

теркәвенә алу турындагы язманың Дәүләт теркәү номеры, даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы бирелгән салым түләүченең идентификация номеры, электрон почта адресы. Әгәр даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларга бирелгән булса, әлеге белешмәләр гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның һәрберсенә карата күрсәтелә;

16) «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә контрактның гамәлдә булу вакыты яисә даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча таныклыкның гамәлдә булу вакыты чикләнгән срокка бирелгән булса;

17) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутын билгеләү, үзгәртү яисә туктату турында, контракт төзү яисә җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукын бирү турында карарлар чыгару даталары һәм мондый карарларның реквизитлары;

18) Татарстан Республикасы законнарында каралган башка белешмәләр»;

2 бүлекнең 2.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары Реестрларына кертелгән белешмәләр (индивидуаль эшкуарның яшәү урыны турындагы белешмәләрдән тыш) җирле үзидарәнең әлеге реестрларны алып бару вәкаләтләренә керә торган вәкаләтле органының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.»;

2 бүлекнең 2.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрына кертелгән һәм җирле үзидарәнең вәкаләтле органнарының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырылган белешмәләрне танышу өчен түләү алмыйча гына мөмкин булырга тиеш.»;

тәртипкә кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);
карарның 2 нче кушымтасында:

3 бүлекнең 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Әгәр кимрәк сроклар даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы бирелгән юридик зат, индивидуаль эшкуар яисә гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы белән килештерелмәгән булса, мондый хокукның гамәлдә булу срогы дәвамында аны билгеләгән Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы инициативасы белән тиешле маршрутны үзгәртү йә юкка чыгару турындагы карар мондый хокукның гамәлдә булу срогы тәмамланган көнгә кадәр йөз сиксән көннән дә соңга калмыйча кабул ителә һәм мондый хокукның гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң үз көченә керә.»;

карарның 3 нче кушымтасында:

1 нче таблицаның 3 бүлегендәге 5 нче юлның 2 нче графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Транспорт чарасын мониторингны тәэмин итү өчен спутник навигациясе приборлары белән җиһазлау»

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып

чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И. А. Габдуллинга йөкләргә.

Район
башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.А. Ямалетдинов

Әлмәт муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрын төзү һәм алып бару тәртибенә кушымта

# Әлмәт муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестры формасы

Табл. № 1

| Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутының теркәү номеры | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутының тәртип номеры | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты исеме | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча арадаш тукталыш пунктлары исемнәре | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча тукталыш пунктлары арасындагы урамнар, автомобиль юллары исемнәре | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутының озынлыгы | Пассажирларны утырту һәм төшереп калдыру тәртибе | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу төре (җайга салына торган/җайга | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларының төрләре, класслары, экологик характеристикалары | | | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдаланырга рөхсәт ителә торган һәр класстагы | Ташучы, Россия Федерациясе субъекты яисә муниципаль берәмлек билгеләгән кышкы чор яисә ел әйләнәсе чор | | | | | Ташучы, Россия Федерациясе субъекты яисә муниципаль берәмлек билгеләгән җәйге чор | | | | | Транспорт чараларының ташу сыйфатына йогынты ясый торган характеристикалары (халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәреннән файдалану мөмкинлеге) | | Транспорт чараларын эксплуатацияләүнең максималь срогы | Даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра башлау датасы | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутын билгеләү, үзгәртү яисә туктату турында карар чыгару датасы | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы бирелгән юридик зат исеме | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы бирелгән юридик затның урнашкан урыны | Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукы бирелгән шәхси эшмәкәрләрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Юридик зат төзү турында язманың Дәүләт теркәү номеры/ шәхси эшмәкәрлекне дәүләт теркәвенә алу турында язманың Дәүләт теркәү номеры | ИНН | Җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга контракт реквизитлары (номеры, бәяләмә датасы) | Ташуларны гамәлгә ашыру турында таныклык реквизитлары даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары буенча (номеры, | Контрактның гамәлдә булу вакыты яисә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | төр | Класс | Экологик характеристикалар | | Рейслар китү көннәре | Рейслар китү вакыты | Туктау вакыты | Рейслар килү вакыты | Кышкы яисә ел әйләнәсе расписаниенең гамәлдә булу чоры (.... нан ....кадәр) | Рейслар китү көннәре | Рейслар китү вакыты | Туктау вакыты | Рейслар килү вакыты | Җәйге расписаниенең гамәлдә булу чоры (.... нан ....кадәр) | сан | Өлеш ( %) | | | | | | | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 | 31 | 32 | 33 | 34 | 35 |